**Татарстан Республикасы**
**Зеленодол муниципаль районы**
**Мулла Иле төп гомуми белем бирү учреждениесе**

# «Бу Мулла Иленең асылы бик күптәннәндер...»

**Башкаручы: Гыйбадуллин**
**Әмир Камил улы, 9 нчы сыйныф**
**Җитәкче: Гыйбадуллина**
**Элиза Фаварисовна, тарих укытучысы**

**Мулла Иле, 2020**

**Эчтәлек**

Кереш....................................................................................................3

I бүлек. «Бу Мулла Иленең асылы бик күптәннәндер...»................................4-12

II бүлек. Мулла Иле авылының ономастикасы................................................13-23

1) Мулла Иле авылының микротопонимиясе.................................................13-17

2) Мулла Иле авылы микротопонимнарын лексик-семантик яктан классификацияләү.....................................................................................17-18

3) Мулла Иле авылының антропонимиясе.....................................................18-23

Йомгаклау..............................................................................................24

Кулланылган әдәбият..............................................................................25

Кушымта..............................................................................................26-35

## Кереш

Туган өен белмәгән,
Туган авылын белерме?
Туган авылын белмәгән,
Туган илен белерме?
(Татар халык мәкале)

Туган ил... Аңа карата булган мәхәббәт балачакта туа, чөнки яшьтән үк туган җирнең, туган якның якты образы һәркемнең йөрәгендә мәңгегә урын ала. Гөрләп торган зур шәһәрме ул, әллә тыныч кына бер авылмы – кайда гына булмасын, һәр кешегә туган җире әйтеп бетергесез якын һәм кадерле.

Туган туфракка тартылу тойгысы туган җирең турында кайгырта белүдә ачык чагыла. Шуңа да туган җиреңнең тарихын белү, анда яшәгән халыкның үткәне, хәзергесе белән кызыксыну – һәрберебезнең изге бурычы, чөнки хәзерге һәм киләчәктәге тормышыбыз белән без үткән буын кешеләренә бурычлы.

Бу хезмәттә туган авылым Мулла Иленең тарихы һәм ономастикасы бергә бәйләп өйрәнелде. Болай эшләү авылның тарихын тулырак итеп күз алдына китерергә ярдәм итә, икенче төрле әйткәндә, җирле ономастик мәгълүматлар тарих шаһитлары буларак, тарихи күренешләрне, вакыйгаларны ачыкларга булыша. Авылның тарихын өйрәнү исә теге яки бу ономастик берәмлекнең барлыкка килүен, куллану үзенчәлеген тулырак итеп күзалларга ярдәм итә.

Билгеле бер территориядә яшәүче халыкның үткәнен, ул гомер иткән авылның тарихын өйрәнү – татар милләтенең язмышын тулырак күз алдына китерергә ярдәм итә, чөнки ул төбәктә яшәгән халыкның тарихы, көнкүреше бөтен татар халкы тарихы белән уртак, бердәм.

Татарстанда бик күп авыллар, торак пунктлар бар. Ул авыллар арасында урта гасырларда нигезләнеп, хәзерге көнгәчә шактый гына гомер иткәннәрен дә, XX гасырда гына барлыкка килгәннәрен дә очратырга мөмкин. Әлбәттә, бу авыллар арасында чал тарихка ия булганнары безнең игътибарны үзләренә ныграк тарта.

Нәкъ менә үзенең тарихы белән ерак гасырларга барып тоташкан һәм борынгы булуы белән дан тоткан авыл – минем туган авылым Мулла Иле.

## I бүлек. «Бу Мулла Иленең асылы бик күптәннәндер...»

XIX гасырның 80 нче елларында Мулла Иле урамнары буйлап атаклы мәгърифәтче Каюм Насыйри узган. Зираттагы кабер ташлры аңа Мулла Иленең бик борынгы авыл булуын, XV гасырда  ук инде монда кешеләр яшәгәнлеге турында сөйләгән. Ул үзенең "Зөя өязе авыллары" дигән хезмәтендә Мулла Иле турында байтак кына кыйммәтле мәгълүматлар урнаштыра.

"Бу Мулла Иленең асылы бик күптәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр. Алар, әүвәл килгәндә, берничә кеше булып килгәннәр. Бәгъзесенең исемнәре мәгълүм түгел. Аларның берсе Муллагол дигән кеше. Янә алар белән берәү бар икән, Шәехби дигән адәм. Ул үзенең бер углы белән килгән. Углы Теләш исемле галим булгандыр; Мулла Илендә дәрес әйткән, мәдрәсә ихъя кылган. Бу Шәехбинең атасы Тәмте дигән кеше. Асыл Кытайдан килгән кешедер. Болгар йортында Кытайдан, Һиндстаннан килгән кешеләр күп булгандыр. Болгар төзек заманда Болгар җирендә ярминкә булып, Һиндстаннан, Кытайдан сәүдәгәрләр килеп сату итәләр икән. Шул сәбәпле аннан килгән кешеләр бәгъзе сәбәпләр белән бу җирдә калганнардыр. Мулла Иле бик кадими авылдыр. Янә аннан соң ике йөз ел чамасында, яки 1660 нчы елларда, Хуҗаштан байтак халык күчеп Мулла Иленә кушылгандыр вә һәм Әҗемнән күп мөселманнар анда күчкәннәрдер. Әҗем дигән авыл (хәзердә Мәҗен дип йөртәләр) Зөядән ерак түгел авылдыр. Хуҗаш хосусында бераз бәяны кичте.

Мулла Иле зияратында бер таш бар — гәрчә бик күптәнге булмаса да, шул Тәмте балаларыннан килгән нәселдер. Бу таш казып язылгандыр, ошбу сүзләр: «1199 сәнә мөхәррәм ае, тәүфикъ алладан, дөнья һәм анда булган нәрсәләр бетәчәк. Бу урында Габделхаликъ бине Габделбакый бине мулла Сәед бине Касыйм бине Ишмөхәммәд Хафиз бине Имбулат бине Ирежмес бине мулла Теләш бине Шәехби бине Тәмти-Хытай әл-Болгари күмелгән». Вә янә моннан башка бер яңарак таш бар, шул югарыдагы кешеләрнең нәселеннәндер, 1850 нче елда вафат булган. Мулла Илендә мөкаддәмрәк бер Вәлид ишан дигән адәм бар икән. Аны монда тәфсыйлән язылмады, якындагы кеше булган өчен (ләкин черновойда бардыр). Вә янә Мулла Иле зияратында бер таш бар, бик күптәнге, бер хатын кешенең кабере булмак кирәк, ошбу рәвешчә язылгандыр: «Тарих тукуз йөз унда Тәвәккәл гаялы Рәҗәб Солтан... Әсәд даре фәнадин даре бәкага рихләт кыйлды». Ләкин югарыда язылган аятьләре ашыгычлык белән язылмады. Бу таш Норлат зияратындагы таш иясенең, ягъни Тәвәккәлнең әүвәлге хатыны булырга кирәк. Ул Тәвәккәл исемле кеше Норлатта булып, әүвәлге хатыны Рәҗәб Солтан Мулла Иленә килеп вафат булгандыр. Бу ташның язылганына 380 еллар буладыр; 1493 нче елларда язылган булырга кирәк."[1]

---

[1]Насыйри К. Зөя өязе авыллары. //Сайланма әсәрләр. – Казан, 1975. – Т.2. – Б.32.

Бу өзектән аңлашылганча, Мулла Иле авылына Болгардан килгән кешеләр нигез салганнар. Алар монда Болгар шәһәрен Батый хан җитәкчелегендәге монгол яулары тар-мар иткәннән соң күчеп килсәләр кирәк.

Тарихтан билгеле булганча, Идел буенда яшәүчеләр бик борынгы заманнардан бирле игенчелек белән шөгыльләнеп көн күргәннәр. Мулла Иле авылы халкының да төп кәсебе игенчелек саналган. Терлекчелек тә хуҗалыкның шактый мөһим тармагы булган. Бакчачылык һәм яшелчә үстерү белән бу авыл халкы бик аз мавыккан.

Игенчелектән кала, Идел буе халкы сәүдә белән шөгыльләнгән. Идел буенда яшәгән барлык милләт халкы арасында татарлар бу өлкәдә өстенлек иткәннәр. Мулла Иле авылы да сәүдә итү өчен бик уңайлы урынга урнашкан. Бу турыда Каюм Насыйри менә нәрсә яза: “Мулла Илендә Тәмте балаларыннан бер мулла Ишмөхәммәд дигән адәм булган. Теләшнең углының углыдыр; яхшы галим кеше вә һәм хафизе кәламулла икән вә һәм кыйраәт гыйлеменә бик маһир кеше булгандыр. Ничә ел Мулла Илендә дәрес әйткән. Ул заманда Мулла Илендә иген белән сату итүчеләр, байлар күп булган. Вә һәм Мулла Илендә зур пристань булган; вә һәм Борындыкта пристань булган. Бәрле сулары, Гәбенә сулары бик зур су булган; вә һәм Зөя суында суднолар, баркалар йөридер икән. Бу авыллар Үтәк каласы тирәсендәге авыллар булганга күрә, Үтәк каласына игендер вә һәм башка төрле малдыр җыеп илтүчеләр, байлар күп булгандыр.”

Димәк, Мулла Иле авылы халкы күрше авылларда яшәүче халык белән күптәннән аралашып яшәгән. Ә тирә-күрше авылларда, татар халкыннан тыш, руслар, мордвалар һәм чуашлар яшәгәнлеге мәгълүм.

Төрле милләт халкы белән аралашып яшәү авылым халкының этник составына тәэсир итми калмаган, әлбәттә. “Мулла Илендәге кайбер нәсел кушаматларында чуваш һәм удмурт телләре белән уртак сүзләр сакланып калган.”[1] Шушы фактлар авылда кайчандыр чуваш һәм удмурт гаиләләренең яшәгәнлеге турында сөйли.

Идел буенда Ьам Зөя елгасының түбән агымында урнашкан чуваш, мордва авылларының Казан ханлыгы чорында әле шактый күп булуы билгеле. 1552 елда Казан ханлыгы тулысынча рус дәүләте составына кушыла, Явыз Иван хөкүмәте, Казан ханлыгының иске идарә аппаратын бетереп, үз администрациясен оештыра. Яңа кушылган бу край белән идарә итү эше «ике зур воеводага» - Казан һәм Зөя воеводаларына тапшырыла. Казан воеводасы Болын ягын, Зөя воеводасы Тау ягын идарә иткән.

Зөя каласы шул чорда руслаштыру сәясәте үткәрү буенча үзәк булып санала. “Бөтен Зөя өязе буенча чукындырылган авыллар саны 34 кә җитә. 34 авылга 6340 кеше диннәрен үзгәртәләр ... Руслаштыру сәясәтенең асылын аңлатмыйча, теге яки бу льготаны алу өчен генә диннәрен үзгәрткән ярлы халык, рәсми рәвештә «христиан-инородецлар» исемлегендә исәпләнсәләр дә,

[1]Саттаров Г.Ф. Татарстанның Яшел Үзән районы Мулла Иле авылының кыскача тарихы һәм ономастикасы.// Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2000. – Б.399-400.

нигездә, мөселман динендә калалар яки беренче уңай мөмкинлек булу белән үз диннәренә чыгалар. Мәсәлән, Зөя өязендәге керәшен татарларының 100 проценты да кире мөселман диненә күчкән.”[1]

Д.А.Корсаков нәширлегендә дөнья күргән тарихи белешмәдә Сазлык янына урнашкан Молвино авылында ясак түли торган - 253, йомышлы - 24 татар кешесе һәм 25 керәшен татары яшәгәнлеге әйтелә.

Мулла Иле авылы Зөя өязенең Косяково волостена кергән. Күрше-тирә авыллар белән чагыштырганда, ул чагында ук шактый бай авыллардан саналган. Авыл халкы, шуңа күрә булса кирәк, миссионерлар тарафыннан салынган налогларны түләп бара алган, алар куйган таләпләрне үтәгән. Шуның нәтиҗәсендә, чукындырылмый калган. Кайбер олы кешеләр сөйрәүләренә караганда, салымнарын түли алмау сәбәпле, христиан динен кабул иткән берничә гаилә булган. Әле 1960 елларга кадәр авылның Татар зираты белән янәшә Керәшен зираты дип йөртелгән зираты да булган.

1881 елның 5 августы белән 1882 елның 4 июнь арасында җир бүлү вакытында килеп чыккан низаглар белән бәйләнешле рәвештә, Мулла Иле авылы «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX в.» хезмәтендә искә алына. 1898 елда бастырып чыгарылган тарихи белешмәдән күренгәнчә, Мулла Иле авылында татарлар гомер кичергән. К. П. Берстель төзегән тарихи белешмә мәгълүматларына караганда, Мулла Иле авылында 2194 татар кешесе яшәгән.

XX гасыр башларында Мулла Иле авылында 600 хуҗалык булган. Авылның ярлы халкы байларга эшләп тамагын туйдырган. Тирә-якта үзләренең байлыклары белән дан казанган байлар Мулла Илендә шактый күп булган: Шакир, Габдулла Хаҗилар, Габдрахман бай, Ибрашев. Электән үк татар халкы өчен хас булган сәүдә эше белән шөгыльләнеп, баеп киткән 7-8 бай гаиләләр арасында Карамышевлар аерылып торганнар.

Авылда өч мәчет эшләгән. Уку-укыту эшләре муллалар кулында булган.

Мулла Иле авылында XIII гасыр ахырында ук мәдрәсә салынган. Шәехби улы Теләш, Теләшнең оныгы Ишмөхәммәт Коръән-хафиз мөгаллимнәр булганнар.

XIX гасырда Мулла Иле мәдрәсәсендә шагыйрь һәм рухани, сәясәтче, вәисиләр хәрәкәтен нигезләүче Баһаветдин Вәисев (1819-1894) һәм аның улы, философ Гайнан Вәисев (1878-1918) укыганнар.

1906 нчы елда Мулла Илендә, Зөя өязендә беренче булып, башлангыч рус-татар мәктәбе ачыла. Аның беренче укытучысы – шушы авыл кешесе Гыйззәтулла Хәйрулла улы Галиәкбәров була (кушаматы Карапай). Гыйззәтулла Мулла Илендә туып-үскән, авыл мәктәбенә йөргән. Алдынгы карашлы әтисе Хәйрулла абзый улын Казанга китереп Госмания мәдрәсәсенә биргән. 1901нче елда ул Казан татар укытучылар мәктәбенә (КТУШ) күчә. Биредә татар теле белән бергә рус телен дә камил белү дәрәҗәсенә ирешә.

Исәпсез-хисапсыз җәмәгать эшләре алып бара. Авылда крестьяннар

---

[1]Бобровников Н.А. Инородческие населения Казанской губернии. – Казань, 1899. – Вып.1. – С.38-39.

мәнфәгатьләрен кайгырта. Шул җәһәттән алпавытлар, адвокатлар, муллалар, депутатлар янына барып, авыл кирәкләрен юллап йөри. Ачлык вакытларында поророфессор Васильев белән бергә мөселман авылларында ашханәләр ачуда катнаша, фәкыйрьләргә казнадан икмәк һәм акча тараттыра. Халыкның ихтыяҗы төшкәндә, казнадан акча алып торыр өчен, "вак бурыч" җәмгыяте ачтыра. Аның иң әһәмиятле эше – Мулла Илендә рус-татар мәктәбе ачу һәм балаларга тирән белем һәм югары әхлак тәрбиясе бирү. Ул Мулла Илендә кызлар мәктәбе дә ачарга ниятләнеп йөргән, ләкин бу максатына ирешә алмый калган: 1911нче елның 14нче гыйнварында, бик кыска гына вакыт авырып үлеп киткән.

Аның белән Казанда бергә укыган якын дусты Шакир Мөхәммәдьяров (1883-1967) – күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист (аның турында "Татар энциклопедиясендә язылган) Г.Галиәкбәровның үлеме турында "Вакыт" газетасында (22нче февраль, 1911нче ел) "Искә төшерү" дигән некрологта мондый юллар бар: "Кешелек җәһәтеннән Гыйззәтулла киң табигатьле, күркәм холыклы, һәрдаим көләч йөзле, һәркемгә йомшак сүзле, ышанычлы иптәш вә фидакарь дус иде. Аның гомерендә бер дошманы булмагандыр... Укымышлы, эшлекле, каһарман йөрәкле Гыйззәтулла... Син Тау ягында яктылык орлыгы чәчүчеләрнең беренчеләреннән идең. Бу орлыклар кара вә үсемлекле туфракка төшкәндер дип ышанам. Ашлык уңар. Синең эзеңнән баручылар Тау ягының чәчәк атып, башак тутырып, дулкынланып утырганын да күрерләр"[1]. Шакир Мөхәммәдьяровны Тукай яхшы белгән, Казанда аның белән гел аралашып яшәгән. 1912нче елның апрелендә Петербургка баргач та, көннәрен аның белән үткәрә. Бу вакытта Шакир әфәнде Петербургта чыга торган "Нур" газетасында (1905-1910) эшли торган була. Тукай да бу редакциягә кереп йөри. Аның редакторы Сафа Баязитов, газета хезмәткәре Кәбир Бәкер, ниһаять, әлеге газетаны чыгаручы Петербург мулласы, атаклы дин эшлеклесе Муса Бигиевләр Тукайны бик хөрмәт итәләр. Тукай Петербургтан кайткач язган "Мәкаләи махсуса" дигән очеркында Шакир әфәнде турында бик яратып яза: "Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров килеп чыкты!" – дип, аны Петербургта күрүенә шатланып туймый. Әлбәттә, алар үзләренең ихлас дуслары Мулла Иле авылының сөекле зыялысы Галиәкбәров турында да искә алмый калмаганнар.
1910 нчы елда татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай үзенең дусты Гыйззәтулла Галиәкбаровларда – Яшел Үзәннең Мулла Иле авылында кунакта була. Тукайның сөекле апасы Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы Хәбибуллина (1877 -1956) да безнең райондагы Бәчек авылында яшәгән, аның кызы Өммөһания Әхмәтсафа кызы Хәбибуллина (1903 - 1975) Бәчектә мәктәп директоры булып эшләгән. Бәчек зиратында аларның каберләре мәңгеләштерелгән .

Казанның алдынгы зыялылары эчендә кайнап, татар халкының бәхете өчен армый-талмый көрәшүче Гыйззәтулланың Габдулла Тукай белән бик тиз аралашып китүе бик табигый. Тукай үзе дә нәкъ менә шундый кешеләргә тартылган. 1910нчы елның җәендә Гыйззәтулла бөек шагыйрьне Мулла Иленә кунакка алып кайта. Алар авылга Кала капкасыннан килеп керәләр (ул

[1]Шәкүров К.Р. Тау ягының мәшһүр затлары.// Яшел Үзән. – 2007. - №49-50.

вакыттагы Казанга йөри торган урам әле хәзер дә Кала капкасы урамы дип йөртелә). Гыйззәтуллаларның йортлары түбән баш мәчете янәшәсендә генә – Олы урамда була.

Тукай Гыйззәтулла йортында бер кич куна. Укыту тәртипләре белән таныша. Ул бит мәктәп өчен дәреслек язган кеше дә. Тукай түбән баш мәчетенә дә кереп чыга. (Мулла Иле мәчетендә 1909нчы елда чыккан Тукай төзегән әдәбият хрестоматиясе саклана. Ихтимал, аны Тукай биреп калдыргандыр) Шагыйрь бу мәчетнең 1873нче елда төзелүен һәм Мулла Иленә тарихи материаллар җыярга килгән Каюм Насыйриның яңа мәчеткә кереп картлар белән сөйләшеп утыруларын белә. Әлбәттә, Баһаветдин һәм Гайнан Вәисовлар (Гайнан Вәисов үзе бу вакытта сөргендә була) турында да искә алалар. Г.Тукай шушы мәчетнең имам хатыйбы Вәлихәйдәр хәзрәт (Шиһаб Мәрҗани хәзрәтләренең дәвамчысы) белән дә фикер алмаша. Вәлихәйдәр хәзрәт Тукайга Шиһабетдин Мәрҗани турында да тәэсирләнеп сөйли. Тукай “Шиһап хәзрәт” шигырен язганда, Мулла Иле мулласы сөйләгәннәр дә аның күңеленә килеп торгандыр. Вәлихәйдәр Котлыәхмәтов – татар тарихында билгеле шәхес. Менә аның турында нәрсәләр язылган: “ XIX гасыр эчендә татар муллаларының иң көчлесе, иң галиме, татар мөселманнарын “саф” көендә саклау юлында бертуктаусыз хезмәт иткән кешеләрнең беренчесе – шөбһәсез, Шиһабетдин Мәрҗани иде. Аннан соң аның юлын дәвам иттерүчеләр: Лаеш өязендә Борһан мулла Габдеррафиков, Сергач өязендә Сабачай авылында Шәрәфетдин Кәлимуллин, Минзәлә өязендә Тәкәрмән авылында Хөснетдин, Зөя өязендә Ачасыр авылында Гыйрфанетдин Сәгъдетдинов һәм шул ук өязнең Мулла Иле авылында Вәлихәйдәр иде. Вәлхәйдәр мулланың кулында Мәрҗанинең күп кульъязмалары сакланган”. (Газыйм Мансуров. Беренче революция елларында татарлар. – Мәскәү: СССР халыкларының Үзәк нәшрияты, 1926нчы елда чыккан китаптан.)

Мәктәп бинасы эчендә (ә мәктәп – Гыйззәтулла Галиәкбәровлар йорты) укытучының яши торган бүлмәсе дә була. Тукай шул бүлмәдә кич кунган һәм үзенең сәер гадәте буенча стенага шигырь дә язып калдырган . Кызганычка каршы, халык хәтерендә ике генә юлы калган:

Мужик үрә чабата,
Үрә-үрә таң ата.

Иртәгесен иртүк Гыйззәтулла Галиәкбәровның әтисе Хәйрулла абзый аларны Зөя каласына озатып куйган.

Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,
Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.
Бу ике дус, берсенә чөнки аларның берсе тиң,
Бертигез тәгълимнәре дә: берсе – дөнья, берсе – дин.[1]

Бөек шагыйрь үзенең бу шигырен, әлбәттә, шушы сәяхәттән соң язган. Тукай милләтнең мәгърифәтләнә баруын – авылдагы татар балаларының да рус телендә иркен аралаша алуларын үз күзләре белән күреп бик сөенгән.

Бөек Тукайның үзен күреп белгән мәчет хәзер дә исән-сау, бөтен авылга иман

---

[1]Тукай Г. Әсәрләр. – 1968. – Б.337.

нуры таратып эшләвен дәвам итә. Авылга Тукай килеп кергән урам хәзер дә Кала капкасы урамы дип атала, Тукай йөргән иң озын урам Тукай исемен йөртә. Тукай урамы белән параллель рәвештә Вәисовләр урамы сузыла. Бөек шагыйрь бу урамда да йөргән һәм Вәисовләр яшәгән урында тукталып уйланып торган. 1908 елда иҗат иткән "Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш" поэмасында ул бит менә шушы Мулла Илендә туып үскән аталы-уллы Баһаветдин һәм Гайнан Вәисовлар (милли азатлык хәрәкәтенең күренекле җитәкчеләре) турында да язган.

1912-1914 елларда Мулла Илендә рус-татар башлангыч мәктәбендә укытучы булып Кайбышев Әкрам ага Галиевич укыта. Ул үзенең хатында: "Свияжск өязендә татар авыллары арасында Мулла Илендә русско-татарская школа бердәнбер иде," - дип яза. Дәресләр бирү системалы булмый, чөнки укытучылар әледән-әле алышынып торалар һәм дин тоткан ата-аналарның күбесе балаларын укырга йөртүдән тыялар. Хатын дәвам итеп Әкрам Гали улы Кайбышев: “Рус-татар башлангыч мәктәбе берничә ел яшәүгә карамастан, беренче чыгарылыш фәкать 1914 елда гына булды. Мәктәпне 12 кеше тәмамлап чыкты. Шулар арасында Әкмал Шаһиев, Кәрим Шоҗагин, Сәлахетдиновларны хәтерлим,” – дип өсти. Беренче бөтендөнья сугышы башлану һәм армиягә алыну сәбәпле, аңа мәктәпне калдырырга туры килә, сңыннан ул Уфа шәһәрендә гомер итә.

1915-1916 елларда мәктәптә Сәет Шиһабетдинов, Таһир Батталовский, Фатыйма Терегуловалар эшлиләр.

Бөтендөнья сугышы авылыбызга да кагыла. Гыйззәтуллин Әбрар, Сабиров Закирулла, Гыймранов Мирзия, Насыйбуллин Кәлимулла һ.б. катнаша.

Шул елларда авыл җирлегенә революция шаукымы бәреп керә.

Октябрь революциясенә кадәр Казан губернасы Урта Идел буендагы иң эре аграр губерналарның берсе булып санала. Эксплуатациянең крепостной һәм капиталистик формалары, милли изү белән бергә кушылып, крестьяннар тормышын кискен дәрәҗәдә авырлаштыра. Соңгы чиккә җиткән җирсезлек авыл халкының алпавытларга каршы баш күтәрелүнең ешаюына сәбәп була.

Казан губернасы буйлап 1917 елның март айларында башланып киткән мондый баш күтәрүләр Зөя өязендә дә интенсив төс ала. 6 нчы июньдә Косяково волосте крестьяннарының җыелышы була. Шуннан соң бер-бер артлы волостьның төрле авылларында алпавытларга каршы баш күтәрүләр башлана. Мондый күтәрелешнең шактый зурысы 1917 елның июлендә Мулла Иле авылында булып уза. Авыл халкы үзен талап, купец дәрәҗәсенә күтәрелгән Карамышевларның җирләрен тартып ала. Алпавытларга каршы оештырылган мондый чыгышлар әледән-әле булып тора. Ләкин баш күтәргән халыкны волостьтан хәрби отряд килеп “тынычландыра”. Бу елларда авылның старостасы Гариф Корсаков (Гариф Карсак) була. Ул Мулла Илендә совет властен урнаштыруда актив катнашучыларның берсе була. Авыл халкы арасында революцион агитация алып баручы коммунистлар - Низам Хаҗиев, Зәйнәп Шоҗагина, Зиннәт Төхвәтуллиннар да була.

1918 нче елның июль-август башында хәзерге Татарстанның бөтен территориясе диярлек акгвардиячеләр гаскәрләре һәм фетнәче ак чехлар корпусы частьлары тарафыннан басып алына.

Гомәр Фәиз улы Саттаров бу вакыйгага кагылышлы истәлекләрендә түбәндәгеләрне яза: “Миңа 10-11 яшьләр чагында, Габдрахман бабам Саттаров (Габдрахман Күке) Мулла Иле авылына аклар керү вакыйгасын болай сөйләгән иде: “1918 елның август айлары. Бөтен кеше кырда, җәйге урак өстендә. Төш алдыннан авыл урамнары аклар белән тулды. Алар, авылны талап, Зөя каласына таба юл тоттылар. Авылдан ике кеше: Хәйретдин Хәйруллин һәм Сәлахи Хәмитов үз теләкләре белән ак бандаларга ияреп китте.” Акларга Зөя каласын алырга насыйп булмый, безнең авылдан 20-25 чакрымдагы Ходяшево дигән рус авылы янында Кызыл Армия части акларның бу отрядын тәмам тар-мар итә.”

Гражданнар сугышыннан соң ук ил өстенә килгән 1921 нче елгы ачлык авыл халкын, туган җирләрен ташлап, ерак җирләргә китәргә мәҗбүр итә. Мулла Иленнән байтак кына гаилә, ачтан үлмәс өчен, Себер, Алтай, Мурманск якларына чыгып китә. Аларның кайберләре берничә ел яшәгәч, кире туган авылларына әйләнеп кайта, ә кайберләре исә гомергә шунда урнашып кала.

Авылыбызның алдынгы карашлы кешеләре ярлы крестьяннар арасында мәдәни-агарту эшләре алып баруны туктатмыйлар. 1918 нче елда Зөя каласында ачылган укытучылар әзерләү курсларын тәмамлап кайткан Зәйнәп Шоҗагина, Галия Әхмәтова, Сәет индюков, Хәлимә Индюкова, Габдрахман Бадамшиннар балалар укыту белән бергә, өлкәннәр арасында да агитация эше алып баралар.

1923 нче елда авылның Аерма дигән урамына “Хутор чалуы” дип аталган зур болынны биләп торган алпавыт Петр Ярахтин йортын сүтеп алып кайталар һәм зур мәктәп салалар. Ләкин яңа мәктәптә авыл балаларына озак укырга туры килми: аны ут төртеп яндыралар.

Мулла Иле авылында шундый хәл килеп туа: укырга теләүче балалар күп, әмма урын юк. 1927-1928 нче уку елында Шакир Карамышевлар (Шакир байлар) йорты мәктәп итеп файдаланыла башлый. Ул дүртьеллык башлангыч мәктәп була. Ләкин бу мәктәп бинасы да 1931 нче елда зур янгын вакытында яна. Шуннан соң район советының рөхсәте белән, Соболевское пристанендагы миллионер Бисковның канцеляриясен, авылга алып кайтып, Әрә эче урамына мәктәп итеп салалар. Бу мәктәп озак еллар халыкка зезмәт итә. 1935 елда җидеелык мәктәпнең беренче чыгарылышы була. Бу мәктәп белән Сәмигуллин Габдулла җитәкчелек итә.

1936 елда җидеелык мәктәп бинасы өлгерә.

Авыл хуҗалыгын коллективлаштыра башлау 1927 нче елларга туры килә. “Беренче бергәләп эшләү өчен ширкәтләр оешты. Ширкәтләргә 7-8 гаилә язылды,” – дип сөйли торган була коллектив турында беренче күмәк коллектив члены Гимранов Мирзия абый. Беренче елларда бу коллективлар зур авырлык кичерә. “Кулаклар төрле юллар белән коллектив эшенә комачауладылар, төрле коткы тараттылар,” – дип сөйли торган була ул.

Соңрак коллектив 8 звено зурлыгындагы 2 артельгә әйләнеп, берсе - “Ирек”, икенчесе “Азат” исеме астында йөри башлый. “Азат” артеле таркала.

1931 нче елда гомуми колхозлашуга күчелә, яңа колхоз “Яна көч” дип атала. Аннан “Яңа көч” һәм “Ирек” артеле белән кушылу нәтиҗәсендә, “Көчле Ирек” исеме ала. Колхозның беренче җитәкчеләре Гобәев Хәлил, Шәрәфиев Минһаҗ, Саттаров Фәйзерахман абыйларга колхозны аякка бастыруда зур тырышлыклар

куярга туры килә.

Соңга таба 512 хуҗалыктан торган колхоз 12 бригадага бүленеп эшли. Өч басулы кыр системасы булдырыла.

“Көчле Ирек” колхозы “Кызыл партизан” колхозы белән берләшеп, “Искра” исемен ала. Авыл халкының 60-70%ы колхозда эшли.

Колхозчылар яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларыннан да мул уңыш алалар.

Бөек Ватан сугышына Мулла Иле авылында да һәрбер гаилә сугышка икешәр-өчәр кешесен озата. Безнең авылдан иң беренче булып фронтка Насыйбуллин Габдулла, Рахматуллин Хәлим, Бикмөхәммәтов Галәтдиннәр китә. Бөек Ватан сугышында катнашучылардан иң карт кешеләр Заһидуллин Хәлил (1897), Насыйбуллин Хәлил (1897), Ибрагимов Абдул (1897), Абдуллин Гиниятлар (1898) булалар. Авылга беренче булып Нуруллин Хафиз, Гиматдинов Ярхәм, Карсаков Гусман, Садыйков Закир, Җәләлиев Госманнар яраланып кайталар.

Күпләр, орденнар, медальләр белән бүләкләнеп, илгә җиңү яулап, туган авылларына исән-сау әйләнеп кайталар. Гыйззәтуллин Әбрар, Җәләлиев Хәбибрахман (сугышта һәлак була) Кызыл байрак ордены белән бүләкләнәләр.

Ватанны саклау өчен киткән ир-егетләрнең 276сы сугыш кырларында, батырларча сугышып, мәңгегә ятып кала.

Ирләре, уллары сугыш кырында булганда, хатын-кызлар да тылда үзләреннән Ватанны саклауга зур өлеш кертәләр. Колхоз кырларында иген үстерәләр, ашлык әзерлиләр. Колхоз хуҗалыгын күтәрүдә Фазлыев Габдрахман күп хезмәт куя. Бөек Ватан сугышы елларының авыр хезмәтен ул оештыра.

Ул вакыт "Көчле Ирек" колхозының рәисе булып Фазлыев Габдрахман абый эшли. Колхозда 12 бригада була. Кырчылык бригадасы бригадирлары: Солтанова Таһира, Тукаева Хәят, Сафина Зәйтүнә, Зиятдинова Зәйнәб, Яруллина Вәгыйзә, Гыйззәтуллина Нурдидә, Фазлыев Борһан, Гаффаров Шәрәфи.

Бу вакытта колхозның бик күп җаваплы тармакларында күпчелек хатын-кызлар эшләгәннәр. Мәсәлән, агроном булып бик озак вакытлар Гайнуллина Рокия эшләгән.

Биктагирова З., Хөсәенова Р., Мингалиева Фатыймалар үзләре ат җигеп йөк ташыганнар.

Сафин Әхмәдулла, Кадыйров Халиклар үз хуҗалыкларындагы сыерларын җигеп, дәүләткә ашлык ташуда булышканнар. Алар һәр сезонда 500-600 ц икмәк ташыганнар.

Укытучылар һәм комсомол яшьләр төнге өмәләр оештырганнар. Алар һәр төнгә кул таяклары белән 25-30ар га җирләрне эскертләгәннәр. Колхозчыларны эшкә актив туплауда бик зур көч куйганнар. Алар хәтта колхоз идарәләрендә кунып, төннән торып колхозчыларны эшкә туплаганнар. Шуның белән беррәттән, укытучылар һәм комсомол яшьләр ындыр табакларында төнге сменаны колхозчылар белән алыштырганнар. Шушы эшләр нәтиҗәсендә “Көчле ирек” колхозы күп кенә уңышларга ирешкән.

1943 елда "Көчле Ирек" колхозы дәүләткә 20241 пот (323 т 8 ц 56 кг) икмәк тапшырган. Самолетлар,танклар төзү өчен 202600 сум акча җыелган. Шул уңайдан Мәскәүдән колхоз рәисе исеменә рәхмәт белдергән телеграмма килгән.

Танклар колоннасына үз өлешләреннән ярдәм итүчеләр: Мифтиев Әбзәл – 50000 сум, Хөсәенов Хәмидулла – 30000 сум. Бу иптәшләргә СССР оборона министрлыгыннан рәхмәт телеграммалары җибәрелгән.

1944 елда авыл буенча колхозчылар арасында 500 000 сум заемнар таратылган. Шуның өчен колхозчылар исеменә рәхмәт телеграммасы килгән.

Сугыш тәмамлангач авыл яңадан тыныч төзелешкә күчә.

1958 ел да мәктәп сигезьеллык итеп үзгәртелә.

1960-1970 нче елларда ”Искра“ колхозларында рәис булып Заһидуллин Габбас һәм Әмиров Рәсимнәр эшли. Беренче мәртәбә колхозда суган үстерелә башлый. Баштагы елларда ул 5 гектар мәйданны били. Аннан соңгы елларда ул тагын да киңәйтелә, колхоз аннан зур уңыш ала.

1974 елда мәктәп бинасы сүтелеп, яңадан төзелә, 1985 елда ул унъеллык итеп үзгәртелә. Шушы елларда мәдәният йорты, китапханә, медпункт, кибетләр, ашханә, ферма комплекслары төзелә.

1986-87 уку елында яңа мәктәп сафка баса. Аны төзүдә колхоз рәисе Әгъзәм Гобәйдуллин һәм күп еллар мәктәп директоры булып эшләгән, авылыбызның аксакалы, шагыйрь Равил Гарәф улы Сәйфетдинов зур өлеш кертәләр.

Әмма 90 нчы елларда бөтен ил кичергән үзгәреш җилләре безнең авылны да читләтеп үтми, кызганычка каршы. Бу чор авылым тормышы өчен шактый катлаулы чор була.

Бүгенге көндә авыл яши, сулый.  Авылым халкы элек-электән үзенең бердәмлеге белән аерылып торган. Хәзер дә күп кенә җәмәгать эшләре бердәм рәвештә алып барыла. Борынгы тарихы булган мәчет авыл халкы ярдәме белән кабат төзекләндерелде, анда балалар, өлкәннәр өчен дәресләр алып барыла. 2012 нче елның көзендә яңа мәчет сафка бастырылды. Мәктәптә, мәдәният йортында әкренләп кенә авыл тарихын тикшерү, тарихи материаллар җыю җайга салынып бара. Әмма Мулла Иленең элеккеге көчен, данын кайтару өчен без – яшьләр – бик күп көч куярга тиеш әле.

## II бүлек. Мулла Иле авылының ономастикасы

### *Мулла Иле авылының микротопонимиясе*

Исемнәрне өйрәнү, теге яки бу географик атаманың килеп чыгуы белән кызыксыну ни өчен кирәк соң? Аларның кайчан һәм ничек барлыкка килүе, нинди мәгънә белдерүләре барыбер түгелмени? Шушы сорауларга җавап бирик. Газета укыйбызмы, радио тыңлыйбызмы, телевизор карыйбызмы, без барыбыз да җир йөзендәге вакыйгаларны, ил-җәмгыять тормышындагы үзгәрешләрне географик атамалар яки топонимнар аша кабул итәбез.

Топонимика фәне географик атамаларның җыелмасын, аларның килеп чыгышын, ясалышын, кулланылыш һәм үсеш эволюциясен, мәгънәсен, таралышын өйрәнә һәм тикшерә. Микротопонимика топонимика фәненең аерым төбәк, шул тирәлек-урын кешеләре өчен генә билгеле булган географик атамалар (микротопонимнар) җыелмасын өйрәнә торган бер бүлеге.

Микротопонимнарның барлыкка килүләре җәмгыятьнең барлык чорларына да хас күренеш. Гасырлар үтү белән кайбер географик объектларның баштагы исемнәре онытылган, халык аларга янә исем кушкан, ә күбесе йә күптәнге, борынгы исемнере белән хәзер дә кулланылышта йөри.

Мулла Иле авылының микротопонимик системасын тәшкил итүче микротопонимнар арасында бик күптәннән исемләнеп, әллә ни зур үзгәрешләр кичермичә, буыннан буынга күчеп, ерак гасырлар аша безнең көннәргә килеп җиткәннәрен дә, әле генә атала башлаганнарын да очратырга мөмкин. Шулай да аларның күбесе борынгы атамалар. Шуларның бер-икесенә тулырак тукталып үтик.

Казаклар юл ярган басу. XX гасыр башларында, Мулла Иле авылының Олы кырында, язын чәчүлек җирләре - имана пае булганда, Мулла Иленең ярлы крестьяннары белән байлары арасында уңдырышлы басулар өчен зур низаг чыга. Байлар, уңдырышлы басуны үзләренә алып, ярлыларга уңдырышсыз кырны бүлеп бирмәкче булалар. Ярлы крестьяннар бунт күтәрәләр, берничә байны һәм куштанны тотып кыйныйлар. Ыгы-зыгы арасында бай куштаннарыннан берәү, яхшы чаптар атка атланып, хәлне хәбәр итү өчен, волость үзәгенә чаба. Косяководан (татарлар Чакау диләр) бер төркем атлы казак ияртеп, тиз арада әйләнеп та кайта. Казаклар атлары белән, ямь-яшел булып үсеп утырган арыш басуын таптатып, баш күтәргән халык янына ашыгалар. Ярсыган ярлы крестьяннарны казак камчысы белән кыйнап тараталар, башлап йөрүче өч агайны волость үзәге Чакауга төрмәгә алып китәләр. Уңдырышлы басу байларга бирелә. Шушы вакыйгадан соң, казак атлары таптап юл салган басу һәм аның янындагы бунт чыккан басу авыл халкы тарафыннан Казаклар юл ярган басу дип атала башлый. Бу атамада туган авылым халкының чәчүлек җире өчен көрәш тарихы, байлар һәм казаклар тарафыннан изелеп, кыерсытылып яшәү тарихы ачык чагылыш таба.

Сәгъди сөргән басу. Электә Мулла Илендә Сәгъди исемле бик ярлы бер кеше яшәгән. Бик тырыш, эшкә уңган кеше булса да, карчыгы һам җиде кыз баласы белән бик фәкыйрь көн иткән. Хатын-кызларга имана пае бирелмәгәнгә, Сәгъди

абзыйның җире бер генә иманадан торган: тугыз кешедән гыйбарәт гаиләдә Сәгъди абзыйның берүзенә генә чәчүлек җире бирелгән. Бер иманалык җир белән тугыз кешене ашату-киендерү бик авыр була аңа. Сәгъди абзый бер елны язын авылыбызның Торна сазы дип атала торган кырының аръягындагы (Кече Өтәк ягындагы) зур бер сазлыклы урынны, көрәк белән канау казып, суын Торна сазына агызып киптерә. Кипкән торфлы сазлыкны сөреп, тырмалап-йомшартып иген чәчә. Торфлы яңа җир булганга иген мул булып үсә монда. Бу җир авыл халкы тарафыннан Сәгъди сөргән басу дигән исем ала.

Мулла Иле авылының микротопонимик системасын тикшерүне урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәрен анализлаудан башлыйк.

Авыл зур булганлыктан, урамнар шактый күп. Урамнарның кайберләре әле генә төзелеп килә (мәсәлән, Яңа урам), а күбесе - бик борынгы: Норлат җыены, Әрә эче, Кармыш җыены, Олы урам, Кала җыены, Хаҗилар җыены, Кибет җыены, Аерма җыены, Канак җыены, Юкәсәр җыены, Тукай урамы, Тегәрҗеп урамы.

Халык телендә авыл ике өлешкә бүлеп йөртелә: Югары баш һәм Түбән баш. Авылның Түбән баш дип аталган очында Юкәсәр дип йөртелә торган бик борынгы урам бар. Бу урам исеменең килеп чыгышын авыл аксакаллары болай аңлата: «Авыл утырган урын урманнар белән капланган бер чорда, бу җирләрдә юкәлек булган, юкәләр шаулап үскән. Кешеләр мунчала ясау белән шөгыльләнгәннәр. Урамга шул чорда ук Юкәсәр исеме бирелеп калган».

Мулла Иле авылы халкы телендә, татар теленең урта диалекты Тау ягы сөйләшләре төркеменә керә торган Норлат сөйләшенә хас булганча, «урам» мәгънәсендә борынгы җыен сүзен куллану хас. Мәсәлән, Норлат җыены - Мулла Иленнән күршедәге Норлат авылына юл чыгып китә торган урам. Бу урамны тагын Тау буе җыены (тау буена, тау итәгенә утырганга) дип тә атап йөртәләр. Кармыш җыены - бу урамга башлап элекке Чабаксар өязенең (хәзерге Чувашстанның Козловка районы) Кармыш авылыннан күчеп килгән гаиләләр утырганнар. Канак җыены - бик борынгыдан килә торган Канак нәселе гаиләләре күп булып утырган урам, Чупак җыены - шулай ук борынгыдан килә торган Чупак нәселе гаиләләре күп булып утырган урам һ.б.

Мулла Иленең буеннан буена сузылган иң озын һам иң үзәк урамы Олы урам дип атала.

Мулла Иле авылына башлап нигез салынган, беренче йортлар корылган урам бүгенге көндә дә Әрә эче дип аталып йөртелә. Бу урам буйлап элек Әрә елгасы аккан. Хәзер инде ул – кипкән, сусыз елга. Язгы ташу вакытларында гына аның үзәненнән Зөя елгасына су ага. Шулай да аның Әрә дигән борынгы исеме халык телендә сакланган.

Мулла Иле авылыннан өч-дүрт километр ераклыкта Прибой дигән рус авылы янында агып узучы елга да Әрә (Олы Әрә) исемен йөртә. Бу елга, Мулла Иле болыннары аша узып, Зөя елгасына коя. Шушы елга башына утырган бер чуваш авылы Әрә башы, Әрәбаш (Чувашстанның Ормар районында), Татарстанның Яшел Узән районындагы Тугай дигән татар авылы җирле халык телендә Әрә дип аталып йөртелә. Шушы елга буендагы Бакырчы авылын Әрә Бакырчысы диләр. Бу турыда К. Насыйри: «...кадим заманнарда,

Бакырчы авылы бик караңгы урман эчендә Әрә суы буена утыргандыр, шуның өчен, Әрә Бакырчысы дип атала», - дип яза. Мулла Иленең көнчыгыш ягында, авылдан бер-ике километр ераклыкта, Зөя буе көтүлекләре, урманнары һәм болыннары (җирле халык телендә - чалулары) башланып китә. Алар дистәләгән километрларга сузылалар.

Хәми чалуы дип атала торган көтүлекнең нәкъ уртасында, борыла-сарыла Кухмар һәм Комсу күлләре яныннан узучы, бер коры үзән сузылып ята. Бу - кайчандыр агым су булган елга юлы. Хәзер инде бу үзән буйлап язын кар сулары гына ага. Шушы сусыз елга үзәнен авыл халкы Үле әрә (Үләрә) дип йөртә. Башкортстанның төньяк сөйләшләрендә әр сүзе «кипкән елга» мәгънәсендә йөри.

Мулла Иле авылының Чана чыгышы, Мәнгәр, Комсу, Кухмар, Чиркәлше һ.б. кебек су чыганаклары атамалары да авылның борынгылыгы турында сөйләүче тарихи-лингвистик факторлар булып торалар.

Чана чыгышы гидронимы составында урын алган чыгыш географик номенклатура термины диалекталь сүз булып санала. «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә (Казан, 1969, 495 б.) чыгыш сүзенең Тау ягының Кама Тамагы һәм мордва-каратай сөйләшләрендә «кизләү» мәгънәсендә кулланылуы теркәлгән. Чана чыгышы – Зөя елгасының Мулла Иле ягындагы (көнбатыш ягындагы) туйра (имән) урманы эчендәге бер чишмә исеме. Көзен туңып каткан сазламык урыннан атка җигүле чана белән барганда, җир астыннан су тибеп, күзләп чишмә чыккан. Шул чишмәне бабаларыбыз Чана чыгышы дип атаганнар.

Мәнгәр - Мулла Иле авылының төньяк эргәсендә агып ятучы кечкенә инеш, елгачыкның исеме. Җәйләре коры килгән елларда бу инеш бөтенләй кибә, корый.

Комсу күле – Зөя елгасының элекке агым юлы бүленеп калу нәтиҗәсендә барлыкка килгән, ике-өч километрга сузылган зур күл. Комсу күленә, төбе һәм ярлары комлы, чиста булудан чыгып, Комсу дигән исем бирелгән.

Мулла Иле болынлыгының Зөя елгасы буендагы бер печәнлеге (җирле халык телендә - чалуы) Комаяк дип атала. Бу атаманың асылында болгар теленнән үк килә торган комаяк сүзе ятса кирәк. Татар теле сөйләшләрендә комайак сүзенең «су төбендәге комлык» мәгънәсендә йөрүе теркәлгән. Мулла Иле халкы комаяк дип, елганың комлы ярында дулкын уйнап барлыкка килгән бик күпсанлы кечкенә-кечкенә чокыр-чакырлы (воронкалы) урынны атый.

Кухмар (Кукмар) күле һәм Чиркәлше ермагы атамалары составында урын алган Кукмар һәм Чиркәлше сүзләренең генезисы мари теле белән бәйләнешле. Кукмар (Кукмара) сүзе марича кук~кугу «зур» +мар~мара (мари халкының үз-үзен атау исеме, этнонимы) сүзләреннән гыйбарәт кушма төзелеш тәшкил итә һәм «зур мари» дигән мәгънә белдерә. Авыл аксакалларының риваять итүләренә караганда, бу күлгә кайчандыр Кукмар исемле чирмеш (мари) батып үлгән, һәм шуңа күрә ул Кукмар күле дип аталган.

Чиркәлше ермагы атамасы составында урын алган чиркәлше топокомпоненты марича «кәкрәйгән, бөгелгән, кыек» сүзе белән бәйләнешле.

Чиркәлше ермагы, чыннан да, кыек, кәкре бөгелеш ясап, Олы Әрә елгасын Зөя елгасы белән тоташтыра.

Зөя елгасының Түбән агымында (Татарстанның Тау ягы территориясендә) борынгы мари топонимик катламының урын алуын башка географик атамалар да раслый. Мулла Иле авылыннан 12 километр төньяк-көнбатыштагы Олы Ачасыр авылы янында Кушаңгар исемле елга бар. Бу гидронимның беренче өлеше төрки-татар куш («пар») сүзеннән, ә икенче өлеше мариларның аңгар «елга», «елгачык» сүзеннан гыйбарәт.

Мулла Иле зираты янындагы зур гына бер күл Кирәмәт күле дип атала. Шушы гидроним составында урын алган кирәмәт «дәһшәтле, үч алучан усал көч», гарәп телендәге карәмәт «могҗиза, илаһи көч» сүзеннән килә. Кирәмәт күле микротопонимы авылның борынгылыгы, аның халкының этник составының компонентлары төрлелеге турында сөйли. Мулла Иле авылына 1240 елларда нигез салган Муллагол, Шәехби һәм башка болгар бабаларыбыз янына яшен суккан агачка – кирәмәтка табынучы мәҗүси чуваш, фин-угор халыкларыннан отяклар, чирмеш, мукшы (мордва) гаиләләре дә килеп утырганнар. Тора-бара алар, ислам дине кабул итеп, үзләре болгар-татар булып киткәннәр. Мулла Иле авылының гидронимиясеннән тыш, антропонимиясе дә, бигрәк тә борынгыдан килә торган нәсел-ыру кушаматлары һәм аларга нигезләнеп ясалган фамилияләр (без аларга соңрак тукталырбыз) әнә шул хакта хәбәр итә. Әлеге төбәккә кагылышлы этнографик, тарихи һәм мифологик чыганаклар да шуны раслый.

Тау ягындагы Казан татарлары авылларына XVII-XVIII йөзләрдә Сергач, Алатырь, Сембер якларыннан мишәрләр килеп чыгып төпләнеп калганнар. Мәсәлән, Мулла Иле авылында Мишәр нәселе (Хәяли Мишәр, Габдулла Мишәр, Габдрахман Мишәр һ.б.). Аларның ерак бабалары булган Ишморат исемле мишәр, Алатырь якларыннан Мулла Иленә килеп, аю биетеп йөргән. Мулла Илендәге бер чибәр кызга гашыйк булган, аңа өйләнгән һәм бу авылда торып калган. Мулла Иле халкы Ишморатның үзенә һәм аның нәсел-нәсәбенә Мишәр кушаматы таккан. Ишморат исеменнан Моратов фамилиясе ясалган.

Шушы һәм башка тарихи-лингвистик фактлар, тулаем алганда, Мулла Иле - Норлат (элекке Зөя өязе) төбәге авыллары халкын XII-XVI гасырларда этник яктан формалаштыруда төп компонент булган болгар-татарлардан тыш, җирле чувашлар, отяклар (вотяклар, ягъни удмуртлар, арлар), мукшылар (мордвалар), чирмешлар (марилар), өлешчә мишәрләр XVII-XVIII гасырларда катнашканнар дигән нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә.

Мулла Иленең берничә авыл капкасы бар. Капкалар, авылдан шул капка аша чыгып китүче юлның кайсы авылга яки башка торак пунктка алып китүенә карап исемләнгән. Элек Зөя каласына (Зөя каласы Зөя өязенең үзәге булган, Мулла Иле авылы шушы өязгә караган) алып бара торган юл чыгып киткән капканы Кала капкасы дип атап йөрткәннәр. Күрше авыл исемнәре белән аталган Норлат капкасы, Соболевское капкасы, Кече Өтәк капкасы бар. Аерма капкасы - авылның аерылыбрак тора торган өлешеннан чыгып китә торган капка.

Географик объектларны атау өчен, Мулла Иле халкы телендә, нигездә, әдәби телебездә кулланыла торган терминнар йөри: тау, ур, каш, кыр, басу, юл, болын, алан, үзән, елга, сукмак, чокыр, яр, күл, саз һ.б. Җирле халык географик объектларны атау өчен, диалекталь сүзләрдән дә файдалана. Шундыйлардан җыен, чалу, әрчү, атау һ.б. кебек диалекталь географик номенклатура терминнарын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Мәсәлән, Мулла Иле халкы җыен дип урамны, чалу дип чабыла торган печәнлекне, әрчү дип кем тарафыннан булса да куаклык-урманнан чистартылган урынны (мәсәлән, Сәгыйть әрчүе), атау дип язгы ташу вакытында су уртасында калган утрауны атыйлар (мәсәлән, Куян атавы).

Мулла Иле авылының һәм аның тирә-юненең ландшафты шактый төрле һәм үзенчәлекле. Монда без күптөрле географик объектларны: тауларны, калкулыкларны, үрләрне, үзәннәрне, чокырларны, басуларны, болыннарны, көтүлекләрне, урманнарны, куакларны, әрәмәлекләрне, юл-сукмакларны; су чыганакларыннан: коеларны, ерганакларны, елгаларны, сазлыкларны, күлләрне һ.б. очратабыз. Мулла Иле авылының микротопонимик материалын лексик-семантик-тематик яссылыкта анализласак, аның шактый кызыклы төркемнәргә бүленүен күрербез.

### ***Мулла Иле авылы микротопонимнарын лексик-семантик яктан классификацияләү***

1. Кеше исемнәренә һәм кушаматларына нигезләнеп ясалган микротопонимнар: Дәули сазы, Шакир сазы, Максим кыры, Закар (Захар) алы кыры, Биктимер күле, Ишми күле, Чупак күле, Миңкә чокыры, Алабирде (Аллабирде) чокыры, Нөркә (Нөркәй, ягъни Нуркай дигән борынгы төрки кеше исеменнән. Мулла Иле халкы борынгы гарәп теленнән кергән нур сүзен нөр дип әйткән булса кирәк. Шушы җирлектә Нөркәй > Нөрә дигән кеше исеме; йөзләрендә нөре юк, нөре качкан, нөрсез, нөре беткән тәгъбирләре ясалган) чалуы, Шоҗак чалуы, Хәмит Тәкә чалуы, Хәми чалуы, Ирмышак (Ирмөхәммәтшәех) чалуы, Бәчүр (Байчура) чалуы, Сөенечкә (Сөенечкәй) басуы һ.б.

2. Туганлык терминнарына һәм сословие титулларына нигезләнеп ясалган микротопонимнар: Кыз күле, Мулла күле, Мулла чалуы, Алпут (Алпавыт) чалуы һ.б.

3. Үсемлекләр дөньясы (флора) белән бәйләнешле микротопонимнар: Юкәсәр урамы, Каенлык асты кыры, Шомыртлык, Усаклык, Зирек күле, Алмагач күле, Утыз имән кыры, Аеравык күле, Арыслан кыягы күле, Җуа аланы һ.б.

4. Хайваннар дөньясы (фауна) белән бәйләнешле микротопонимнар: Куян атавы чалуы, Күке аланы, Торна сазы, Бүре сазы, Бурсык сазы, Бака күле, Кәрәкә күле һ.б.

5. Географик объектның төсенә карап аталган микротопонимнар: Кызыл балчык чокыры, Караяр, Кызьлъяр, Кара саз, Ак комлык һ.б.

6. Географик объектның зурлыгына, күләменә, формасына, санына карап аталган микротопонимнар: Олтамак (Олы тамак), Нәзексаз, Озын атау, Кече урман, Олы саз, Олы Әрә, Кече Әрә, Олы кыр, Кече кыр, Озын атау, Кәкре күл, Тар урам, Кыек биш, Яр асты алты [пай печәнлек], Үзән сигез һ.б.

7. Охшату-чагыштыру аша исемләнгән метафорик образлы микротопонимнар: Тегәрҗеп урамы, Тустаган күле, Иләк сазы һ.б.

8. Географик объектның (башлыча икенче бер географик объектка карата) урнашу урынына карап исемләнгән микротопонимнар: Әрә буе көтүлеге, Кормаш төбәге чалуы, Тирмән алды чалуы, Стуйла турысы чалуы, Алдагы Бучок чалуы, Арттагы Бучок (Василий>Бучок) чалуы, Читән эче печәнлеге, Каенлык асты кыры, Карама турысы басуы, Торна сазы кашы кыры, Алдагы чокыр, Арттагы чокыр һ.б.

9. Эш-хәрәкәт, берәр вакыйга белән бәйләнешле микротопонимнар: Этөргән сазы, Тире кырган чалуы, Дуңгыз аткан күпере, Биктимер үлгән күл, Дегет кайнаткан чокыр, Янган саз, Яңакиртә корган саз, Әҗәл (булган) күле, Шөлдермә ермагы (шөлдерәп ага торган елгачык), Казаклар юл ярган басу, Сәгъди сөргән басу һ.б.

10. Берәр әйбернең, билгенең табылуы, булуы белән бәйләнешле микротопонимнар: Мүкле саз, Наратлы чокыры, Төнбоеклы күл, Балыклы күл, Кабык күпер, Таш юл һ.б.

11. Башка телләрдән кергән сүзләргә нигезләнеп ясалган микротопонимнар: Становой чалуы, Матрос чалуы, Хутор чалуы, Паровой күле, Кирәмәт күле, Кукмар күле, Чиркәлше ермагы һ.б.

12. Октябрь революциясеннән соңгы вакыйгаларга, тормыш-көнкүрешкә бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән микротопонимнар: Азат кыры, Хөррият урамы, Клуб урамы, Ферма урамы һ.б.

## *Мулла Иле авылының антропонимиясе*

Антропоним термины кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата.

Һәр телнең билгеле бер рәсми һәм рәсми булмаган номинатив категорияләрден гыйбарәт антропонимик системасы бар. Рәсми антропонимик категория булып, исем, отчество һәм фамилия саналса, рәсми булмаган категориягә кушаматлар карый. Хәзерге татар телендә, рус теле тәэсирендә формалашкан, өч элементтан торган антропонимик система гамәлдә йөри. Бу система исем+отчество+фамилия категорияләрен үз эченә ала. Татар теленең антропонимик системасында иң борынгы атау-эндәшү категорияләре булып исем һәм кушамат санала. Фамилия белән отчество исә боларга караганда соңрак формалаша.

Мулла Иле авылының антропонимик системасы гомумтатар милли антропонимик системасының бер өлеше, аның органик бер кисәге булып тора. Анда, бер тамчы суда диңгез суына хас булган барлык сыйфатлар булган кебек, милли антропонимик системабызга хас үзенчәлеклер чагылыш таба.

Мулла Иле авылындагы кеше исемнәре һәм алардан ясалган отчестволарның килеп чыгышында, ясалыш-төзелеше һәм кулланылышында башка авыллардагы һәм шәһәрләрдәге татар кеше исемнәреннән һәм отчестволарыннан әллә ни зур аермалар юк.

Кеше исемнәре, отчестволар һәм фамилияләр белән беррәттән, шәхесне атау өчен кушаматлар киң кулланыла. Кушамат аралашуны, аңлашуны җиңеләйтү, кем турында сүз алып баруны төгәл, ачык итү өчен ярдәм итә торган бер антропонимик чара булып тора. Кушаматлар зур өч төркемгә бүленә: 1) нәсел-ыру кушаматлары, 2) шәхси кушаматлар, 3) коллектив-террриториаль кушаматлар.

Аларның һәрберсенең үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекләре бар. Нәсел - ыру кушаматы бер генә шәхескә карамыйча, туганлык мөнәсәбәтләрендә торган бөтен бер төркем, берничә гаилә, нәсел кешеләрен үз эченә ала. Бу төр кушаматларның үзенчәлекле ягы булып, буыннан буынга күчүчәнлек, дәвамчанлык санала. Димәк, нәсел-ыру кушаматы шул ук вакытта аны билгеле бер нәсел, гаилә эченә алып керә.

Шәхси кушамат дип, конкрет шәхескә караган кушаматны атыйлар. Конкрет шәхесне белдереп, шәхси кушамат һәрвакыт берлек санда гына кулланыла. Нәсел-ыру кушаматларыннан аермалы буларак, барлык шәхси кушаматларның да диярлек, барлыкка килү мотивлары, сәбәпләре билгеле.

Коллектив-территориаль кушаматлар дип туганлык мөнәсәбәтендә тормаган, ләкин территориаль яктан бәйләнешле булган кешеләр коллективын берләштергән кушаматларга әйтәләр. Болар күбесенчә күплек санда кулланыла, ә берлектә кулланылса, шул төркемнең, коллективның бер вәкилен генә күрсәтә.

Кушамат - Мулла Иле антропонимиясе өчен бик характерлы күренеш. Авыл зур булганлыктан, күпчелек гаиләләрнең кушаматлары арасында иң киң таралганнары һәм шактый актив кулланыла торганнары – шәхси һәм нәсел-ыру кушаматлары. Коллектив-территориаль кушаматлар төбәк антропонимиясендә урын алмый.

Шәхси кушаматлар килеп чыгышы буенча реаль чынбарлыкка туры килергә һәм аның белән тыгыз бәйләнештә булырга тиеш. Башлыча мондый кушаматлар шәхес характерының үзенчәлекләренә, профессиясенә һәм башка шәхси үзенчәлекләргә мөнәсәбәтле рәвештә туа. Кайбер шәхси кушаматлар кеше теге яки бу сәеррәк эшне, вакыйганы башкарганнан соң тагылып кала.

Нәсел кушаматлары - бер нәселга караган берничә гаиләнең төп атамасы. Ул, буыннан буынга күчеп, сакланып килә. Шуңа да бу төр кушаматларның килеп чыгышын һәм мәгънәләрен татар халкының борынгы бабалары яшәгән чордан, болгар катлавыннан һәм башка кардәш һәм кардәш булмаган телләр материалларыннан эзләгәндә ачыклап була. Мулла Иле борынгы болгар авылы булганлыктан, килеп чыгышлары белән бик борынгы заманнарга караган нәсел кушаматлары бу авылда шактый. Шуларның кайберләрен, генетик яктан тикшереп, этнолингвистик төркемнәргә бүлеп карыйк.

1. Борынгы төрки телдә, татар халкының борынгы бабалары саналган Идел-Кама болгарлары телендә һәм иске татар телендә булып та, хәзерге татар

телендә кулланылмый торган архаик сүзләргә нисбәтле нәсел-ыру кушаматлары.

Мулла Иле авылында борынгы гомумтөрки тел сүзларенә нисбәтле, борынгы төрки сүзләргә нигезләп ясалган нәсел-ыру кушаматларыннан: Карсак, Көтич, Күлүк, Мөкә, Чупак, Чүри, Тапай һ.б.ларны күрсәтә алабыз.

Татар телендә карсак сүзе «дала төлкесе», «корсак» мәгънәсен аңлата. Мулла Илендә берничә гаиләне үз эченә алган Карсак нәселе бар. Татар теленең көнбатыш диалектында карсак сүзе «тәбәнәк, кыска» дигәнне белдерә.

Борынгы төрки телдә көтич сүзе балаларны орышу өчен кулланылган. Мулла Иле авылында бер нәсел әлегә кадәр Көтич кушаматын йөртә.

Борынгы төрки телдә күлүг сүзе (1 нче мәгънәсе) «данлы», «билгеле», күлүг (2 нче мәгънәсе) сүзе «даими түгел», «күчүчән» мәгънәләрен белдергән. Күлүг (3 нче мәгънәсе) кеше исеме булып кулланылган: Күлүг чур, Күлүг тутук, Күлүг уруну һ.б. Мулла Илендә, бик борынгыдан башлап булса кирәк, бүгенге көндә дә бер нәсел Күлүг кушаматын йөртә: Гаяз Күлүг, Галләм Күлүг, Минһаҗ Күлүг һ.б.

Мулла Иле авылында Мөкә кушаматын йөртүче нәсел дә бар.

Авылда уннан артык гаиләне үз эченә алучы Чупак нәселе бар. Шушы нәсел утырган кырый урам Чупак җыены, а шул урам башындагы күл Чупак күле исемен йөртә. Борынгы төрки телдә чабак сүзе «вак балык» мәгънәсен белдергән. Электә вакчыл ир кешене «чабак ир» дип атаганнар. Иске татар телендә Чабак, Чабакай кебек балык исемнәренә нигезләнеп ясалган кеше исемнәре дә кулланылышта йөргән. Татарларда, шушы борынгы исемнәргә нигезләнеп, Чабак, Чапак, Чабакай кушаматлары, бу кушаматлардан Чабаков, Чапаков, Чабакаев, Чупаков фамилияләре ясалган.

Мулла Иле авылындагы Чүри нәсел-ыру кушаматы (мәсәлән, Хәлимә Чүри, Гыйбадулла Чүри һ.б.) да килеп чыгышы белән борынгы төрки телдәге Чүри исеменә барып тоташа. Чүри исеменең асылында исә чүр «файда» сүзе яки чура «батыр кеше, гаскәри, сугышчы, дружинник, игенче, кол» сүзе ятса кирәк.

Мулла Иле авылында, Болгарый кушаматыннан тыш, генезислары белән шулай ук болгар теленә нисбәтле Канак, Кондык, Кырым, Кәпә, Маши, Ызай һ.б. нәсел-ыру кушаматлары бар.

Мулла Иле авылында йөзгә якын кешене үз эченә алган Канак нәсел-ыруы бар. Шушы нәсел вәкилләренең күбесе Канаков (Канакова) фамилиясен йөртә. Мулла Иленең Канак нәселе гаиләләре күп булып утырган зур урамнарыннан берсе Канак җыены яки Канак урамы дип атала.

Канак нәсел-ыру кушаматы һәм авылы исеменең килеп чыгышы борынгы болгар һәм аргу телләрендә «каймак», «сөт өсте» мәгънәсендә кулланылган канак сүзеннән ясалган Канак исеменә нисбәтле.

Кондыр дигән нәсел-ыру кушаматының (мәсәлән, Гариф Кондыр, Сәлим Кондыр, Рәхимулла Кондыр һ.б.) килеп чыгышы да болгар теленә кайтып кала. Р-з авазларының тәңгәллеге (ротацизм) болгар теленә хас фонетик күренеш булып санала. Болгарлар кыйммәтле мех бирә торган су җәнлеге «кондызны» кондыр дигәннәр.

Мулла Иле авылындагы Кәпә нәсел-ыру кушаматы да (мәсәлән: Гариф Кәпә, Әхәт Кәпә һ.б.) үзенең генезисы белән борынгы төрки-болгар телләренә барып тоташа. Борынгы төрки телдә күбә, татарча көбә сүзе «кольчуга, металл кием» мәгънәсен белдергән. Идел-Кама болгарларында тимерчелек эше һөнәрчелекнең әһәмиятле һәм алга киткән тармагы булган. Болгар тимерчеләре сөңгеләр, уклар, кистәннәр, көбәләр һәм башка кораллар хәзерләгәннәр.

Маши нәсел-ыру кушаматының асылында да болгарларның Маши («поши», башкортча мышы - «поши») исеме ятса кирәк.

Шулай итеп, килеп чыгышлары борынгы төрки һәм болгар теленә нисбәтле нәсел-ыру атамалары, ерак заманнардан башлап буыннан буынга күчеп килә торган мөһим тарихи-лингвистик фактор булган хәлдә, Мулла Иле авылының байтак кына нәсел-токым кешеләренең ерак бабалары Идел-Кама болгарлары булуын, Мулла Иле халкының этногенезын формалаштыруда болгарларның төп этник компонент тәшкил итүләрен раслый.

2. Чуваш теленә нисбәтле нәсел-ыру кушаматлары.

Урта Идел-Кама территориясендә халык һәм милләт булып формалашу процессында татарлар бу җирлектә яшәгән чуваш, удмурт, мари кабиләләрен яки халык төркемнәрен үз этносларына катнаштырганнар, аларны акрынлап ассимиляцияләгәннәр. Татар халкы этносына катнашкан әлеге кабиләләрнең яки халык төркемнәренең телләре белән мөнәсәбәтле географик атамаларның һәм нәсел-ыру кушаматларының барысы да хәзергәчә сакланмаса да, шактые шушы регионда халык һәм милләт булып формалашкан татарларның теленә (ономастикасына) кабул ителгән хәлдә, гасырлар аша, безнең көннәргәчә исән-имин килеш килеп җиткән.

Элекке Зөя өязе төбәгенә караган Мулла Иле авылында да килеп чыгышлары чуваш теленә нисбәтле Пелтер, Кәппәй, Капайт, Майур, Күрәчә, Жаржыган, Кака, Прыйх һ.б. кебек нәсел-ыру кушаматлары бар.

Пелтер нәсел-ыру кушаматының асылында чуваш телендәге пелтер «былтыр» сүзе ята. Борында чувашларда пелтер «былтыр», болгар-татарларында былтыр «узган ел» исемнәре кулланылышта йөргән. Мәҗүси чувашлар, болгар һәм башка төрки халыклар усал көчләрне, җен-пәриләрне алдау өчен, ир балага Пелтер, Былтыр «узган ел» исемен кушканнар. Шулай эшләгәч, усал көчләр бу балага яманлык, усаллык эшли алмыйлар, аның яңа гына тууын белми калалар, имеш.

Мулла Иле авылында чувашларның Пелтер («Былтыр») исеме, нәсел-ыру кушаматына әверелеп, безнең көннәргәчә сакланып килеп җиткан, һәм ул бу нәселгә кайчандыр борынгы заманнарда Пелтер исемле чувашның нигез салуын хәбәр итә.

Прыйх нәсел-ыру кушаматының (мәсәлән, Хәбир Прыйх, Габдулла Прыйх, Сәлимхан Прыйх һ.б.) генезисы да чуваш теленә барып тоташа. Чувашларда парыйх сүзе «куян» мәгънәсендә кулланыла, чуваш телендәге куян «заяц» (чуваш телендә шулай ук хорон «куян» сүзе дә кулланылышта йөри) сүзен алмаштырып, табулаштырып әйтү өчен хезмәт итә.

Борынгы монголлар һәм төрки халыкларда кулланылышта йөрган 12 хайван циклына нигезләнгән ел исәбендә куян елы да булган, һәм ул авыр, афәтле ел

булып саналган. Менә шуңа элек сүзнең магик көченә, тылсымына ышанган төрки халыклар, өйдә кечкенә бала яисә яшь терлек (бәрән, кәҗә бәтие, бозау, колын, дөя баласы һ.б.) булганда, куян сүзен әйтмәскә тырышканнар, аны башка сүз белән алмаштырганнар, табулаштырганнар, ягъни әйтүне тыйганнар. Мәсәлән, татарлар куян сүзен, куянга хас сыйфатлардан чыгып, озын колак, кыек күз сүзтезмәләре белән, чувашлар, куянның «прыйх» итеп төчкерүенә нигезләнеп, прыйх сүзе белән алмаштырганнар. Мулла Иле авылында кайчандыр Прыйх нәсел-ыру кушаматының барлыкка килүе әлеге нәселгә нигез салган шәхеснең куян кебек «прыйх-прыйх» итеп төчкерү гадәтена бәйләнешле (ягъни охшату-чагыштыру җирлегендә туган кушамат) булса кирак.

Мулла Иле авылында чуваш телендә «мактанчык» мәгънәсен белдерә торган каппай, капайт сүзләре белән бәйләнешле Кәппәй (каппай «мактанчык» сүзенең нечкә әйтелеш алган кәппәй вариантыннан ясалган) һәм Капайт насел-ыру кушаматлары бар.

Мулла Иле авылындагы Күрәчә нәсел-ыру кушаматының асылында чувашларның курача пухмас «күрмәс, карамас, ягъни сукыр» дигән тәгъбире ята. Бу тәгъбирнең курача өлеше Мулла Иле авылы татарлары телендә нечкә әйтелеш (күрәчә) алган хәлдә, Күрәчә нәсел-ыру кушаматына әверелгән һәм Кадыйр Күрәчә, Равил Күрәчә антропонимнарында безнең көннәргәчә сакланган.

Ясалыш белән үткән заман хикәя фигыль формасыннан гыйбарәт булган Жаржыган нәсел-ыру кушаматы бар: Галиәхмәт Жаржыган, Равил Жаржыган, Нурания Жаржыган һ.б. Жаржыган кушаматының асылында чувашларның шаршаган («сасыган») сүзе ята. Элек чувашларда Шаршаган сүзе мәҗүси кеше исеме булып йөрган. Борынгыда төрки халыкларда, гаиланең баштагы балалары үлеп барса, усал көчләр чираттагы яңа туган нарасыйга тимәсеннәр, аны читләтеп үтсеннәр, бала исән-имин калсын дигән теләктән чыгып, ямьсез, шыксыз эчтәлекле сүзләрне дә балага исем итеп кушу гадәте булган. Шушы гадәт нигезендә чувашларда Шаршаган («Сасыган»), Сөрсегән, Ачы (Әче), казахларда Сасыкбай, Сөрсенбай, Сөрсенбикә һ.б. кебек кеше исемнәре барлыкка килгән.

Мулла Иле авылында чувашларның Шаршаган исеме, Жаржаган әйтелешен алып, әлеге нәсел-ыру кушаматына әверелеп сакланган.

Мулла Илендәге Кәләмәч нәсел-ыру кушаматының (мәсәлән, Рашит Кәләмәч һ.б.) асылында да чувашларның келемеҫ «хәерче», «теләнче» сүзе ята.

3. Удмурт теленә нисбәтле нәсел-ыру кушаматлары.

Мулла Илендә генезислары фин-угор телләренә кайтып кала торган кайбер нәсел-ыру кушаматлары һәм фамилияләре дә урын ала. Мәсәлән, Мулла Иле авылындагы берничә нәсел-ыру кушаматының этимологиясен удмурт теле мисалында ачыклап була.

Мулла Илендәге Пузкар нәсел-ыру кушаматының (мәсәлән, Госман Пузкар, Гомәр Пузкар һ.б.) асылында удмуртларның пузкар «оя» сүзе ятса кирәк.

Билгеле бер нәселне, ояны дәвам иттерүче бердәнбер вәкил булган ир балага элек Пузкар кушаматы тагылган һәм аның нәселе әлеге кушамат белән аталып йөртелә башлаган. Бу кушамат XIII-XVI йөзләрдә Мулла Иле авылында удмурт

гаиләләренең да яшәве һәм аларның тора-бара тулысынча татарлашуы турында сөйли.

Удмурт телендә тютю «чебеш», «каз бабкәсе» мәгънәләрен белдерә. Тютю («чебеш») сүзе борынгы удмурт телендә кеше исеме булып та йөргән: Тютю, Тютюк. Мулла Иле авылындагы бер нәсел Туту кушаматын йөртә: Минһаҗ Туту, Гомар Туту, Фәтхелислам Туту һ.б. әлеге нәсел кушаматының асылында удмуртларның Тютю мәҗүси исеме яки кушаматы ятса кирәк. Бик кечкенә булып туган ир балага яки тәбәнәк, кечкенә булып туган ир балага, яки тәбәнәк, кечкенә буйлы кешегә «чебеш» мәгънәсен белдерә торган сүзгә нигезләнгән исем кушу яки кушамат тагу, антропонимик универсалий тәшкил итә. Мулла Иле авылында кешенең буе кыскалыгына, кечкенәлегенә нигезләнеп барлыкка килгән: Кечтерт, Метеки, Печтеки, Кәрлә, Чукмар, Тукмак, Мөкертә һ.б. кебек кушаматлар да бар.

Мулла Иле авылында мәгънәсе белән без югарыда сүз алып барган Канак («каймак», «сөт өсте») нәсел-ыру кушаматы белән мәгънәдәш Нокы (удмуртча нокы сүзе «каймак», «сөт өсте» дигән мәгънә белдерә) нәсел-ыру кушаматы да бар: Хәбибулла Нокы, Равил Нокы, Кәрим Нокы һ.б.

Чәпи нәсел-ыру кушаматының (мәсәлән, Хәйретдин Чәпи, Хәбир Чәпи һ.б.) лексик мәгънәсен дә удмурт теле материалында аңлатып була. Удмурт телендә чипей сүзе «чуртан» мәгънәсен белдерә. Бу сүз Мулла Иле авылы халкы телендә чәпи әйтелешен алып, ерак бабалары удмурт булган нәселнең кушаматына әверелгән хәлдә, буыннан буынга күчә-күчә, безнең көннәргә килеп җиткән. Тешле, үзсүзле кешегә татарлар Чуртан, удмуртлар Чипей, руслар Щука кушаматы кушканнар.

Мулла Иле авылында татар теленә нисбәтле нәсел-ыру кушаматлары, әлбәттә, зур күпчелекне тәшкил итә. Алар арасында кош-корт исеме белән аталганнары: Күке, Торна, Чәүкә, Карга; имезүче хайван исемнәренә нигезләнеп ясалганнары: Тәкә, Бүти, Кәҗә, Аю; бөҗәк атамаларына нигезләнгәннәре: Таракан, Чикерткә, Чебен; үсемлек атамалары белән аталганнары: Ясмык, Чөгендер; көнкүреш предметы исемнәре белән аталганнары: Күмер, Шакма, Чүлмәк, Салма; кешенең физик җитешсезлеген яки характер билгесен белдерә торган сүзгә нигезләнеп ясалганнары: Кыек авыз, Калып баш, Дәү баш, Чәчрәп китим, Ташкисәр, Качкын, Аткыч; кеше исемнәрен кыскартып әйтү җирлегендә барлыкка килгәннәре дә: Апу, Апуч (<Габдулла), Кәбүч (<Кәбирулла), Тәлүч (<Тәлибулла), Мөти (<Мотыйгулла), Пыскый (<Фәсхетдин), Шипыйк (<Шәфигулла) һ.б. бар.

Күреп үткәнебезчә, туган авылның ономастикасын җентекләп тикшерү туган телнең тарихи үзенчәлекләрен һәм үсешен, татар халкының тарихын һәм этногенезын өйрәнүдә үзеннән шактый зур фәнни өлеш кертә.

## Йомгаклау

Бу эшебездә без Мулла Иле авылы тарихы һәм ономастикасына кагылышлы мәсьәләләрне мөмкин кадәр тулы итеп фәнни нигездә яктыртырга тырыштык. Мулла Иле авылының тарихына һәм ономастикасына комплекслы якын килеп, ягъни аларны бергә бәйләп тикшерү максат ителде. Болай эшләү авылның тарихын тулырак һәм җентекле итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Икенче төрле әйткәндә, җирле ономастик мәгълүматлар, тарих шаһитлары буларак, тарихи күренешләрне, вакыйгаларны ачыкларга булыша. Региональ тарихны өйрәнү исә, үз чиратында, татар халкының тарихын, аның тормыш укладын, этнографиясен, этногенезын һәм тел тарихын өйрәнергә ярдәм итә.

Бу хезмәтне язган вакытта күп кенә фәнни хезмәтләр, тарихи материаллар белән танышырга туры килде.

Мулла Иле авылының тарихын тикшергәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин: Мулла Иле – бик борынгы татар авылларының берсе. Аның нигезләре болгар чорына ук карый, аңа XIII гасыр урталарында ук нигез салынган. Башлап нигез салучылары булып, Болгар дәүләте монголлар тарафыннан җимерелгәч (1236-40 нчы еллар), туган илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган берничә болгар кешесе санала. Болар арасында Муллагол һәм Шәехби дигән бабаларның исемнәре мәгълүм.

Авылның болгар авылы булуын раслаучы башка дәлилләр – ышандырырлык фактлар. Мәсәлән, әлеге көнгәчә Болгарый кушаматының кулланылуы, XIV-XVII гасырларга караган кабер ташларының саклануы (кызганычка каршы, алдарак чорларныкы сакланмаган), алардагы кулъязма истәлекләр – болар барысы да авылның болгар авылы булуы турында сөйлиләр.

Тел өлкәсендә сакланып калган кайбер үзенчәлекләрдән борынгы болгар теле үзенчәлекләрен дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, авылда сакланып килгән нәсел кушаматлары - Кондыр, Канак, Карсак, Кәтич, Күлүк, Чупак, диалекталь сүзләр – сөрәкә (балык сөзү коралы, ятьмә) – болар борынгы гомумтөрки телгә караган сүзләр.

Мулла Иле авылының ономатискасын тикшергәндә, кайбер үзенчәлекле атамаларның булуы тарих өлешенә ачыклык кертә һәм Мулла Иле авылының борынгы болгар авылы булуын тагын бер кат раслый.

Татар авылының берсе мисалында фактик материалларны, тел һәм тарих җәүһәрләреннән, мирасыннан гыйбарәт күп төрле һәм күп телле географик атамаларны өйрәнү, халкыбызның телен, тарихын һәм бик тирәндә яткан тамырларын белергә, милли тарихыбызның этник төпкелләрен өйрәнергә, дөньяви тарихыбызны язарга булыша. Һәркемне туган җиренә, аның урман-кырларына, тау-үзәннәренә, елга-суларына, юл-сукмакларына, болын-көтүлекләренә, сала-калаларына нәкъ менә аларның тарихларын, атамаларының кайчан, кемнәр тарафыннан бирелүен һәм нәрсә аңлатуларын, лексик мәгънәләрен белү, белергә теләү берләштерә, туган җирнең, туган якның кадерен, газизлеген һәм якынлыгын шулар арттыра, милли тамырларны шулар ныгыта, беркайчан һәм берничек тә өзелмәслек итә.

## Кулланылган әдәбият


1. Бобровников Н.А. Инородческие населения Казанской губернии. Выпуск 1. – Казань, 1899.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Т.2. – Казан, 1975.
3. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2000.
4. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан, 1989.
5. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? – Казан, 1998.
6. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. – Казан, 1992.
7. Саттаров Г.Ф. Татар топонимиясе. – Казан, 1998.
8. Сәйфетдинов Р.Г. Мулла Иле – изге җир.// Мәгариф. – 1996. - №11.
9. Сәйфетдинов Р.Р. Тукай һәм Тау ягы.
10. Тукай Г. Әсәрләр. – Казан, 1968.
11. Шәкүров К.Р. Тау ягының мәшһүр затлары.// Яшел Үзән. – 2007. - №49-50.

**Кушымта**





Авыл күренешләре.



Яшелчә бакчасы, 1947 ел.



Өмәдә, 1948 ел.



Келәттә, 1951 ел.



Югары баш мәчете, 1953 ел.





Алмагач бакчасында.



Иске мәктәп күренеше.




Яңа мәктәп ачу тантанасы, 1986 ел.



Мәктәп укучылары, 1953 ел.



Кичке мәктәптә укучылар.



Авылым аксакаллары җыелышта.



Иске мәдәният йорты янында.



Авыл яны табигате бик матур. Елга-инешләр күп, калкулык-үрләр, басу-кырлар, сазлар, күлләр, печәнлекләрнең күбесе исемле.





Сабантуй алдыннан.



Армиягә китүче егетләр.





Тормыш мизгелләре.